**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

***04.10.2018*** № ***09-05-161***

Казан ш.

Татарстан Республикасының сатып алулар һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү буенча комиссия турында Положениега үзгәрешләр кертү турында

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ
ТЕРКӘЛДЕ
***23.10.2018***
ТЕРКӘҮ НОМЕРЫ: ***4939***

«Татарстан Республикасының сатып алулар һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү буенча комиссия турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елда кабул иткән УП-569 номерлы указына ярашлы рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының сатып алулар һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү буенча комиссия турында Татарстан Республикасының сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 6 июлендә кабул ителгән 09-16-88 номерлы боерыгы белән расланган Положениега (Татарстан Республикасы сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 23 мартында кабул ителгән 09-16-42 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге эчтәлектәге 17.6 пункт белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«17.6. Шушы Положениенең 17.1, 17.3 һәм 17.4 пунктларында күздә тотылган мотивлаштырылган нәтиҗәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) шушы Положениенең 16 пунктындагы «б» подпунктының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» подпунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм уведомлениелардагы мәгълүматны;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүматны;

в) шушы Положениенең 16 пунктындагы «б» подпунктының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» подпунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм уведомлениеларны алдан карау нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган нәтиҗәне, шулай ук, шушы Положениенең 24, 25.3, 26.1 пунктларына ярашлы рәвештә, карарларның берсен яисә башка төрле карар кабул итү өчен тәкъдимне.».

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Рәис О.А. Редько